# Тема:
# Халык авыз иҗатында кыска жанрлар
# Мәкальләр һәм әйтемнәр



FokinaLida.75@mail.ru

# Халык авыз ижаты - Фольклор.

## Фольклор -

**Халык ижаты**
**народное творчество**

**англ. folk – халык- народ,**
**lore –акыл,  мудрость, знание**

**совокупность обычаев, обрядов,**
**песен и других явлений народного быта**





FokinaLida.75@mail.ru

# Халык авыз иҗатында кыска жанрлар

Бишек җырлары - Колыбельная песня

Юаткыч - Потешка

Саналмышлар - Считалка

Тизәйткеч - Скороговорка

Табышмак - Загадка





FokinaLida.75@mail.ru

# Фольклорның тагын нинди кыска жанрларын беләсез?

**Мәкаль** - ***Пословица***

- Тормыштагы төрле гыйбрәтле күренешләр гомумиләштереп, образлы итеп әйтелгән тапкыр гыйбарәләр.

**Әйтем** - ***Поговорка***

Нинди дә булса тормыш күренешенә читләтеп (образлы итеп ) бәя биргәндә кулланыла торган сүзләр тезмәсе.



FokinaLida.75@mail.ru

# Нәрсә соң ул мәкаль ?

- « Мәкаль » сүзе безгә гарәпчәдән кергән. Анын мәгънәсе урынлы сүз яки тиешле урында әйтелгән акыллы сүз була. Мәкаль кыска һәм тирән мәгънәле булганга, аны халык хикмәте дип атау барлык халык фольклорында бик киң таралган.



FokinaLida.75@mail.ru

## Мәкальгә хас сыйфатлар:

- ✔Грамматик яктан төзек, җыйнак җөмләләрдән тора;
- ✔Үзенә хас ритм һәм мәгнә басымы белән әйтелә;
- ✔Гадәттә үзара рифмалашкан җөмләләрдән тора, беренче җөмлә сәбәпне белдерсә, икенсесе нәтиҗәсен күрсәтә;
- ✔Фикер күп мәгнәле булырга мөмкин;
- ✔Гасырлар буе җыелган тәҗрибәне чагылдыра;
- ✔ Киләчәк буынга үгет-нәсыйхәт бирә.



FokinaLida.75@mail.ru

# Мәкаль турында мәкальләр

- « Мәкаль  җыймыйм – акыл җыям»
- « Мәкаль  – сүзнең җиләге».



FokinaLida.75@mail.ru

# Татар халык мәкальләре – күңел байлыгы



FokinaLida.75@mail.ru

## Мәкальләр, эчтәлекләре ягыннан, нинди темаларны яктырта?

- \- Ата-ана, бала-чага;
- \- Тел, сүз, сөйләм әдәбе;
- \- Сүздә тору, сер саклау, дуслык;
- \- Акыл, белем алу, уку-язу;
- \- Авыз иҗаты, сәнгать;
- \- Кеше һәм аның холкы;
- \- Туган җир, ватан;
- \- Батырлык һәм куркаклык һ.б.



FokinaLida.75@mail.ru

# Хезмәт. Һөнәр. Ялкаулык.

- Эш сөйгән үкенмәс.
- Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
- Башлаган эшне ташлама.
- Чалкан ятып шалкан үсми.
- Иренчәк ике эшләр.
- Хөрмәт сөйсәң, хезмәт сөй.



FokinaLida.75@mail.ru

# Кешенең рухи йөзе – холкы.

- Таш белән атканга аш белән ат.
- Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт.
- Күрергә матур, акылга такыр.
- Сабыр төбе – сары алтын.
- Яхшы холык дошманыңны үз итә.
- Иркенлек турылыкта, күркәмлек холыкта.



FokinaLida.75@mail.ru

# Гаделлек. Гаделсезлек.

- Без капчыкта ятмый.
- Хаклык өчен утка кер, суга төш.
- Йөз явызлыкны бер дөреслек җиңә.
- Дөрес сөйләгән ялгышмый.
- Бер ялганласаң, икенче чын сүзеңә дә ышанмаслар.



FokinaLida.75@mail.ru

# Тел. Җыр. Белем. Акыл.

- Ана теле бер булыр.
- Иле барның теле бар.
- Ил җыр белән яши.
- Белем байлыктан кыйммәт.
- Белемдә көч.
- Акыл – дәрья, уй диңгез.
- Акыл яшьтә түгел, башта.



FokinaLida.75@mail.ru

- Слово

**Әйткән сүз – аткан ук.**

**Слово не воробей, вылетит не поймаешь.**

- О дружбе

100 сум аксаң булганчы, йөз дустың булсын.

Старый друг лучше новых двух.

Дуслар кайгыда беленә.

Друзья познаются  в беде.



FokinaLida.75@mail.ru

# Мәкальләрне дәвам итегез- Продолжите пословицы.

- Аерылганны аю ашар, …
- Җиде кат үлчә, …
- Юлга чыксаң, …
- Җирнең нуры – кояш, кешенең нуры - …



FokinaLida.75@mail.ru

# Әйтем

- **Эчтәлегенә әйләнә – трәне танып белергә булыша,акылны үстерә торган тотрыклы, гадәттә, образлы тәгъбир. Әйтемнәр тулы җөмлә булып җитә алмыйлар, ягъни алар фикер-хөкемнең бер өлешен генә тәшкил итәләр.**
- **“Ике куян тоту”, “Иш янына куш”, “Тырнак астыннан кер эзләү”**



FokinaLida.75@mail.ru

Ә й т е м н ә р
Шатлыгыннан баш күккә тигән.
Күзгә төртсәң күренми.
Ике күзем ңурт  булды.

Акыл дәрәҗәсе
Акыл өләшкәндә абзар артында калган.
Йөзгә бер тулмый.
Акны карадан аермый.
Бармакка чорнарлык та акылы юк.
Әлифне таяк дип тә белми.
Акылы юлда адашмаслык кына.
Капчык белән суккан.
Башына тай типкән.
Тилебәрәне орлыгы ашаган.
Утыз тугызлы.
Бер тактасы ким.
Улчәве таманрак
Акылы керәле дә чыгалы.



FokinaLida.75@mail.ru

# Мәкальләр

« Һәр халыкның мәкале үзенчә. Менә шулардан мәкальнең иң зур күпчелеге һәр халыкның үз иҗтимагый-тарихи тормыш тәҗрибәләреннән һәм ышануларыннан, аның үз теленең иҗат һәм сурәтләмә мөмкинлекләренә таянып барлыкка килгәнлеге аңлашыла. Аның кайчан туа башлаганы билгесез, авторлары исемсез, шулай ук аның әле дә туудан туктаганы юк. Тормыш һәм халык яшәгән җирдә аның тумавы мөмкин дә түгел: чөнки кеше үз табигате буенча шагыйрь, үзе тәҗрибә һәм иҗат иясе. Шунлыктан мәкаль башлап ялгыз кеше авызыннан әйтелсә дә, һәр уңышлы иҗатны эләктереп алучы халык аны телендә саклый, тагын да шомарта, чөнки аны гомуми мәгънәгә күтәрүче халык үзе бөек шагыйрь, үзе тормышны иҗат итүче бөек даһи ул»

(Нәкый Исәнбәт)



FokinaLida.75@mail.ru

***Мәкаль – ул гарәп сүзе, аталар, картлар сүзе, Халык хикмәте...***

**Сүз күрке мәкаль,**
**ир күрке сакал.**



FokinaLida.75@mail.ru

# МӘКАЛЬЛӘРНЕҢ ТОРМЫШТАГЫ РОЛЕ ҺӘМ ӘҺӘМИЯТЕ

- аталар сүзе яки халык хикмәте булуы
- безне иҗтимагый фикергә ия итүе
- тел байлыгы булу ягыннан
- сәнгать әсәре булуында
- халыкның культурасын, тарихын, этнографиясен өйрәнү өчен материаллар бирә
- тәрбияви әһәмияте
- аңны һәм тормышны үзгәртү коралы булуында



FokinaLida.75@mail.ru

Өй эше:

1.Мәкальләр өйрәнеп килергә.

2.Мәкаль язып карарга.



FokinaLida.75@mail.ru